# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

# АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

# МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 12 09.04.2015ел

Мюд авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымнарын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү һәм үткәрү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, “Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы КАРАР итте:

1. Мюд авыл җирлеге Советының инициативасын хупларга һәм 2015 елның 24 маенда якшәмбегә, 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге территориясендә 1 төркем инвалидлардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан тыш, 18 яшькә җиткән һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын ел саен бер тапкыр түләргә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтергә килешәсезме:

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пунктларны төзекләндерүне оештыру:

А. Татар Сөнчәле авыл җирлеге чикләрендә Үзәк урамы буенча урнашкан урам юлларын һәм җирле әһәмияттәге күперләрне карап тоту 80000 сум;

б. П. МЮД Сөлчә елгасы аша күпер төзү 39400 сум

пионер ш. п. буаны чистарту 18200 сум

2.Су системасын ремонтлау

А. Иске Мокшино авылы 20000 сум күләмендә суүткәргеч системасын ремонтлау,

б. п. пионер 10000 сум күләмендә су башнясын урнаштыру,

Татар Сөнчәлесе авылы 30000 сум суүткәргеч челтәрен алыштыру

3. Күмү урыннарын оештыру

А. Д. Әхмәткә зират коймасы 30000 сум.

РИЗА КАРШЫ».

3.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум түгәрәген билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Башкарма комитетына 18 яше тулган сайлаучылар исемлеген төзергә һәм раслау өчен Мюд авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә тапшырырга.

5.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә гамәлдәге законнар нигезендә Мюд авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru һәм мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә:

- ТР, Аксубай районы, МЮД поселогы, Үзәк урамы, 27;
- ТР, Аксубай районы, Иске Мокшино авылы, Зеленая ур., 1;
- ТР Аксубай районы, Татар Сөнчәле авылы, Тукай ур., 12

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге
Совет Рәисе: А.Г.Семенушкин